**IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МЕТРӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ LVI УТЫРЫШЫ**

КАРАР

27 январь 2025 ел №93

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Метрәй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Метрәй авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә турында» 2023 елның 17 маендагы 64 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 16 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 сентябрендәге 338-ФЗ номерлы Федераль законына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районыны Прокурорының 2025 елның 14 гыйнварындагы 02-08-01-2025 номерлы протестын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Метрәй авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Метрәй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Метрәй авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә турында» 2023 елның 17 маендагы 64 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8 бүлекнең 8.3 пунктындагы 5 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«5) белем һәм квалификация турында документ;".

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам

Метрәй Авыл җирлеге башлыгы Шамгунов И.В.